| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.04.2020 № 200

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 30 сентябрендәге 892 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтү срогын озайту турында» 2020 елның 1 апрелендәге 241номерлы карары нигезендә һәм коронавирус инфекциясе таралу куркынычын минимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 30 сентябрендәге 892 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә 2.1 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 30 сентябрендәге 892 номерлы карары белән билгеләнгән дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең өстәмә компенсациясен алучы 20,0 мең сумга кадәр уртача керемле гражданнарга, 2020 елның 30 сентябренә кадәр түләп бетерелә торган социаль ярдәм чараларын, аларны алу өчен гаризаны кабат тапшырмыйча бирүне 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов